СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.37А, с.Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН УШМЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Совет ур., 37А нче йорт, Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 1-20 от 01 февраля 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 1-32 нче номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве уздыру өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Мамадыш муниципаль районының рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль

берәмлеге Уставының 89 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы  авыл җирлеге башлыгы Р.М. Ганиевка  йөкләргә.

Башлык, Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы  авыл җирлеге Советы рәисе Р.М. Ганиев

1 нче кушымта
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының
01.02. 2023 ел, № 1-20 карарына
1 нче кушымта.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелүче үзгәрешләр

1. 1 Статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1 Статья. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең исеме һәм хокукый статусы

1. «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә җирлек статусы бирелде.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алаг таба текстта - Җирлек).

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы составына керә.»;

2. 5 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында «аларның үтәлешен тикшереп тору» сүзләрен «җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү таләпләрен үтәү буенча төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

3. 11 статьяның 7 пунктының 2 абзацында «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

4. 12 статьяның 3 пунктындагы 3 абзацында «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5. 12 статьяның 3 пунктындагы «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

6. 13 статьяның 5 пунктындагы «Җирлек сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

7. 13 статьяның 8 пунктында:

- беренче җөмләдәге «Җирлек Сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

-икенче җөмләдә «Сайлау комиссиясе утырышлары» сүзен «Территориаль сайлау комиссиясе утырышлары» сүзләренә алмаштырырга;

8. 13 статьяның 12 пунктындагы «Җирлек Сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

9. 20 статьяның 5, 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты, үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) яисә Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш, гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса.»

6. Гавами тыңлаулар уздыру турындагы карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән алып аларны үткәрү көненә кадәр Җирлек халкы җирлек башлыгына гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән муниципаль норматив хокукый актның халык алдында тыңлауларына чыгарыла торган проектларына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да.».

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көне эчендә җибәрелергә тиеш.

Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерүне оештыра. Әлеге тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.»

10. 20 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Иҗтимагый тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарылырга

(халыкка җиткерелергә) яисә Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар үткәргән көннән 5 көн эчендә урнаштырылырга тиеш, әгәр гамәлдәге законнарда башка срок каралмаган булса.»

11. 20 статьяның 10, 11 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе Җирлек уставы һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм халык тыңлауларын үткәрү вакыты һәм урыны турында җирлек халкына алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән, шул исәптән, аны Мамадыш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән алдан ук таныштыруны, җирлек халкы тарафыннан фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен, шул исәптән рәсми сайт аша, җирлек халкының җәмәгать тыңлауларында катнашуын тәэмин итә торган башка чаралар, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне), шул исәптән аларны рәсми сайтка урнаштыру юлы белән бирүне күздә тотарга тиеш.

Җирлек Уставы һәм (яисә) Җирлек Советының норматив хокукый актлары белән әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән материалларны һәм мәгълүматны урнаштыру, җирлек кешеләренең муниципаль хокукый акт проекты буенча үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен тәкъдим итү мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук рәсми сайтның мондый максатларда мәҗбүри файдалану таләпләрен үтәп, халык алдында тыңлауларда катнашу өчен «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин, аны куллану тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

11. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау кагыйдәләренә, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләренә, проектларына күрсәтелгән расланган документларның берсенә, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә, рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен һәм объектларны капиталь төзелеш объектларыннан башка төргә үзгәртү мәсьәләләре буенча, җирдән файдалану

һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булмаганда ачык тыңлаулар яисә иҗтимагый фикер алышулар шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә үткәрелә.»;

12. 29 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек Советының рәсми исеме – «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы»;

13. 41 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктаткан, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;

14. 33 статьяның 1 пунктында «Җирлек Сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

15. 34 статьяның 1 пунктының 13 пунктчасын төшереп калдырырыга;

16. 44 статьяның 5.1 өлешендәге 12 пунктының «а» һәм «б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләренә алмаштырырга;

17. 46 статьяның 8.1 өлешендәге 12 пунктының «а» һәм «б» пунктчасында «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләренә алмаштырырга;

18. 42 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек башлыгы вазыйфасының рәсми атамасы – «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгы».;

19. 48 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлеге Башкарма комитетының рәсми атамасы – «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы  авыл җирлеге башкарма комитеты.»;

20. 50 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктчасының 3 абзацындагы «төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота» сүзләреннән соң «төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра» сүзләрен өстәргә;

21. 50 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлекнең башкарма комитеты Муниципаль контрольне тормышка ашыруга вәкаләтле орган булып тора.
Муниципаль контроль өлкәсендә җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:
1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;
2) җирлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән башка вәкаләтләр.
Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре җирлек башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгели торган хокукый актлар нигезендә йөкләнергә мөмкин».»;

22. Уставның VII бүлеген төшереп калдырырга;

23.  59 статьяның 3 пунктында «һәм Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «һәм территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

24. 67 статьяның 2 өлешендәге 17 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

25.  80 статьяда:

а)  3 өлешне төшереп калдырырга;

б)  7 өлештә:

4 абзацны түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:
«- җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрендә» ;

түбәндәге  эчтәлектәге  яңа абзац өстәргә:

«-Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләүче документларда.»;

в) 9 өлешнең беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакция дә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясында каралган очракларда бюджет керемнәренең баш администраторлары Исемлеге;»;
«-Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясында каралган очракларда бюджет керемнәренең баш администраторлары Исемлеге;».